| Республика Татарстан<br>Совет Верхне-Чершилинского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Югары Чыршылы авыл<br>җирлеге Советы |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 сентябрь 2019 ел № 13

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 пункты, Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрүне тәкъдим итәргә:

«Сез, I төркем инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, уку йортларының көндезге бүлекләрендә укучы студентлардан тыш, Югары Чыршылы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 300 сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә тоту белән килешәсезме?:

- Түбән Чыршылы авылы, Горький урамы күперенең оске капламын ремонтлау;

- Югары Чыршылы авылы мәдәният йорты территориясен койма белән әйләндереп алу һәм төзелеш материаллары сатып алу;

- Югары Чыршылы авылы Ленин урамы буенча юл чокырларын ремонтлау өчен бетон сатып алу;

- Югары Чыршылы авылында Сабантуй бәйрәмен үткәрү өчен бүләкләр алу;

- МТЗ-82.1 тракторына ягулык сатып алу;

- МТЗ-82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу.

ӘЙЕ ЮК?"

2. Әлеге карар мәгълүмат стендлары һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш.

Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов